ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.03.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 585**

Зеленодольск муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча Координация советын төзү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 17 декабрендәге 2203 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы яшьләрен патриотик тәрбияләү» муниципаль ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү буенча координацион совет булдыру.
2. Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү буенча координация советы турындагы нигезләмәне расларга (1нче кушымта).
3. Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү буенча координация советы составын расларга (2 нче кушымта).
4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 06 февралендәге «Зеленодольск муниципаль районында патриотик тәрбия бирү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча координацион совет оештыру турында» 204 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев

1нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
22.03.20021 ел №585

Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү буенча координацион совет турында
**нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча координация советы (алга таба - Совет) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы консультатив-киңәшмә орган булып тора, ул Зеленодольск муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләүне үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү максатларында төзелгән.

1.2. Совет үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, норматив хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

## 2. Совет эшчәнлегенең төп бурычлары һәм юнәлешләре

2.1.Советның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Зеленодольск муниципаль районы яшьләренә гражданлык, патриотик тәрбия бирү һәм аны тормышка ашыруда өстенлекле юнәлешләр формалаштыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү;

– Муниципаль хакимият органнары, иҗтимагый берләшмәләр, ветераннар һәм яшьләр оешмалары арасында ведомствоара хезмәттәшлекне үстерү;

- Патриотик тәрбия өлкәсендә норматив хокукый һәм оештыру-методик базаны үстерү;

- Иҗтимагый оешмаларда, берләшмәләрдә, клубларда яшьләрне патриотик тәрбияләү мәнфәгатьләрендә кадрлар сайлау һәм әзерләү эшендә катнашу;

– Яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүнең актуаль проблемаларын хәл итүдә, шул исәптән гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген координацияләү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- Гражданнарга патриотик тәрбия бирү, патриотик тәрбия бирү өлкәсендәге чараларны күздә тоткан муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) эшләү һәм тормышка ашыруда катнашу.

-Гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларны һәм берләшмәләрне яклау, матди базаны ныгыту һәм үстерү, фәнни-методик яктан тәэмин итү.

## 3. Советның структурасы һәм оешмасы

3.1. Совет рәисе-Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

3.2. Совет составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре җитәкчеләреннән һәм кызыксынучы органнар һәм оешмалар вәкилләреннән оеша. Советның сан составы 20 кеше.

3.3. Совет составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

3.4. Совет утырышлары кирәк булган саен, әмма елына кимендә 2 тапкыр уздырыла.

3.5. Совет үз эшен ел саен үткәрелә торган чаралар планы нигезендә төзи. Чаралар планы Координация советы әгъзалары тарафыннан тәкъдимнәр кертү юлы белән бергә формалаштырыла һәм Координация советының чираттагы эш утырышында раслауга чыгарыла.

3.6. Совет эше планын формалаштыру һәм Совет утырышында карау өчен мәсьәләләрне әзерләү Совет секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Шул максаттан секретарь:

- Совет утырышының көн тәртибе проектын әзерли, Совет утырышларына материаллар әзерләүне оештыра;
- Совет әгъзаларына утырышны үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмати материаллар белән тәэмин итә;
- Совет утырышлары беркетмәсен алып бара һәм рәсмиләштерә, беркетмәне Совет әгъзаларына җибәрә һәм кабул ителгән карарларның практикасында кулланылу барышы турында аларга хәбәр итә.

3.7. Совет утырышына сорауларны әзерләү өчен җаваплылык докладчыларга йөкләнә. Сорауларны әзерләү өчен җаваплы кеше чыгышның тезислары, белешмә материаллары, утырышка кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, Совет секретарена тапшыра.

3.8. Утырыш беркетмәсен Советның җаваплы секретаре алып бара. Рәсмиләштерелгән беркетмә утырыш үткәрелгәннән соң 5 көн эчендә рәис имзасына тапшырыла

3.9. Совет утырышы, әгәр анда Совет әгъзаларының исемлек составының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

3.10. Совет утырышлары ачык булып тора.

3.11. Совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә, Совет Рәисе яки аның урынбасарлары утырышта рәислек итүче тарафыннан имзаланган беркетмәләр рәсмиләштерелә.

3.12. Советның үз компетенциясе нигезендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим характерында

## 4. Совет вәкаләтләре

Үз бурычларын гамәлгә ашыру өчен Совет түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1. Билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск муниципаль районы структур бүлекчәләреннән, учреждениеләр һәм оешмалардан, Эчке эшләр органнарыннан һәм аларның вазыйфаи затларыннан Совет компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматны соратып алырга.

4.2. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә эшләүче гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә үз эшчәнлеген алып баручы иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә мәгълүмат алу өчен мөрәҗәгать итәргә.

4.4. Совет секретаренә совет эшчәнлегенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә.

4.5. Яшьләргә патриотик тәрбия бирү мәсьәләләрен хәл итү буенча Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары, төрле иҗтимагый берләшмәләрнең эшен анализлау;

4.6. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның барышы һәм Совет эшчәнлеге кысаларында аларга йөкләнгән бурычларны үтәү турында Ярдәмче программаны башкаручыларның докладларын һәм хисапларын тыңлау.

4.7. Советның эшчәнлеге Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 17 декабрендәге 2203 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы яшьләрен патриотик тәрбияләү» ярдәмче программасы гамәле тәмамлангач туктатыла.

1нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
22.03.20021 ел №585

**Зеленодольск муниципаль районының патриотик тәрбия бирү буенча координация советы составы**

| | |
|---|---|
| **Совет рәисе** Лулаков Денис Владиславович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| **Совет рәисе урынбасары** Волчкова Ольга Александровна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча бүлек начальнигы |
| **Совет секретаре** Чегодаева Гүзәл Равил кызы | «Форпост» ФООП Яш. (С,Ук.) ЗҮ МБУ инструктор-методисты |
| **Совет әгъзалары:** | |
| Гыйльманова Мария Михайловна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе җитәкчесе урынбасары |
| Нигъмәтуллин Динар Азат улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге начальнигы |
| Миндибаев Фидан Газыйм улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлегенең шәхси состав белән эшләү бүлеге начальнигы урынбасары (килешү буенча) |
| Багрянский Дмитрий Евгеньевич | Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы буенча хәрби комиссариат бүлегенең гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм чакыру бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Сметанина Екатерина Михайловна | «Форпост» ФООП Яш. (С,Ук.) ЗҮ МБУ директоры |
| Гыйбадуллин Марсель Мансур улы | «Исток» ОМК» МБУ директоры |
| Братухин Владимир Валерьевич | «Юнармия» җирле үзидарәнең ВВПОД Штабы начальнигы |
| Гыйззәтуллин Тәлгать Рифкать улы | Зеленодольск муниципаль районы ветераннар Советы Рәисе(килешү буенча) |
| Мурзабаев Марсель Ишмурз улы | «Сугышчан туганлык» хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм ветераннар җәмгыятенең Зеленодольск бүлеге рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Әһлуллин Илһам Илсур улы | ТР ДОСААФ РОГО Зеленодольск МБ идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Павлова Нина Николаевна | Зеленодольск муниципаль районындагы «Гнездышко «Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют» ДКУ стационар бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| Осипова Ирина Геннадьевна | ЗМР «РМКМҮ» МАУ фәнни-методик бүлеге мөдире |
| Бутусов Алексей Александрович | Зеленодольск шәһәренең «Поиск» төркеме командиры (килешү буенча) |
| Хәсәнов Руслан Рәзим улы | Зеленодольск муниципаль районы «Иҗат үзәге» ӨББ МББУ патриотик тәрбия бирү буенча методисты |
| Ярмөхәмәдов Илнур Мәнҗит улы | «Яшел Үзән механика көллияте» ДАҺБУнең ТИН укытучысы (килешү буенча) |
| Евстафьев Сергей Александрович | Тормыш иминлеге нигезләре укытучысы, инженер<br>«Зеленодольск медицина училищесы» ДАҺБУ (килешү буенча) |
| Лотфуллина Елена Борисовна | Зеленодольск машина төзелеше һәм мәгълүмати технологияләр институтының (КНИТУ-КАИ филиалы) ТИ укытучысы (килешү буенча) |